
И туган тел,
и матур тел...

# ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ: ГАМӘЛИ АСПЕКТ









## ӘДӘБИ НУРЛАР

4
кисәк

Хөрмәтле укытучылар,
укучылар һәм ата-аналар!

«Әдәби нурлар» кулланмасының дүртенче кисәге – **гамәли карталар** әдәбият теориясенә кагыла. Алар ментальь карталарның, дәрәҗәләргә бүленгән ике яклы эш карталарының һәм әдәби анализ өчен кирәкле терәк схемаларның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Татар әдәбиятыннан беренче тапкыр мондый форматта эшләнгән әлеге кулланма әсбап укучыларның белемен системага салырга һәм мөстәкыйль күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.


Биредә тупланган карталар әдәбият дәресләрендә әсәрне анализлаганда яки әдип иҗатын өйрәнгәндә, әдәби чорларны яки теоретик төшенчәләрне үзләштергәндә, шулай ук олимпиадаларга әзерләнгәндә, төп кулланма әсбап булып хезмәт итәчәк.

# Әдәбият теориясе: гамәли аспект (26 карта)

Укучыларның күбесе әдәбиятны өйрәнү юлында нигез булып торган теоретик мәгълүматны, төшенчәләрне яттан белә, әмма бу материалны гамәлдә куллана алмый. Шуңа бәйле рәвештә кулланманың дүртенче өлешендә **теоретик төшенчәләрне гамәлдә куллануга йөз тоткан гамәли карталар** тәкъдим ителә. Мондый төр карталарның бер ягында – тәңгәлләштерүгә биремнәр, икенче ягында шушы теоретик төшенчәләргә бәйле традицион биремнәр тәкъдим ителә. Бу карталар халык авыз иҗатын өйрәнгәндә, әсәр анализына бәйле теоретик төшенчәләрне үзләштергәндә, төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларга әзерләнгәндә файдалы материал булачак. Эшне бу рәвешле оештыру укучыларга катлаулы гыйльми-нәзари төшенчәләрне аңлау һәм үзләштерүне җиңеләйтергә мөмкинлек бирәчәк.

# 4.1. Тел-сурәтләү чаралары (троплар)

БИРЕМ. **Шигырьләрдән өзекләрне укып, аларга туры килгән теоретик төшенчәләрне (атамаларны) табып әйтегез.**



Ничә тапкыр гизеп үттем инде
Җир шарының орбитасын мин;
Тик беркайда очратмадым сине,
Табалмадым, табылмадың син.

Х. Туфан



Җыр өйрәтте мине
хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомерем минем моңлы
бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар
җыр булып.

М. Җәлил

**МЕТАФОРА**
**ЧАГЫШТЫРУ**
**МЕТОНИМИЯ**
**ЭПИТЕТ**



Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми.

Ф. Кәрим



Туктаганнар күрмәгә иртүк
табигать күркене,
Күктә аккошлардай
ак күчмә болытлар төркеме.

Г. Тукай

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне атагыз.**

- Әдәби ачыклау ярдәмендә образ тудыра торган тел-сурәтләү чарасы ______________________________ дип атала.

- Бер күренеш, әйбер, кешене башка күренеш, әйбер, кешегә хас сыйфат, билге белән атау ярдәмендә барлыкка килә торган тел-сурәтләү чарасы ______________________________ дип атала.

- Күренешләрнең охшашлыгына яки каршылыгына нигезләнеп, яшерен чагыштыру хасил иткән тел-сурәтләү чарасы ______________ дип атала.

- Нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән тел-сурәтләү чарасы ______________________ дип атала.

# 4.2. Тел-сурәтләү чаралары (стилистик фигуралар)

**БИРЕМ. Шигырьләрдән өзекләрне укып, аларга туры килгән теоретик төшенчәләрне (атамаларны) табып әйтегез.**



Рәхмәт, дөнья,
Язмышның син миңа
Тоташ шигырьлесен сайладың, –
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Һәм өздереп елан сайрады!

Зөлфәт



Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары,
Андагыдай шаулый торганнар.

Һ. Такташ

**КАБАТЛАУ**
**ИНВЕРСИЯ**
**АНТИТЕЗА**
**РЕФРЕН**



...Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр...
...Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр...

М. Җәлил



Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен,
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен,
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара.

М. Әгъләмов

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне атагыз.**

- Шигырьнең һәр строфасында яки строфаның билгеле бер урынында кабатланып килә торган тезмә ярдәмендә формалашкан стилистик фигура ______________________________ дип атала.

- Сүзләрнең, образларның, төшенчәләрнең капма-каршы куелуына нигезләнгән стилистик фигура ______________________________ дип атала.

- Әдәби әсәрдә сүзләр, гыйбарәләр, җөмләләр, текстның бер өлешенең нинди дә булса кагыйдәгә нигезләнмичә, ирекле кабатлануына нигезләнгән стилистик фигура ______________________________ дип атала.

- Җөмләдә сүзләрнең гадәти тәртибен үзгәртү ярдәмендә яңа эмоциональ төсмер бирүгә корылган тел-сурәтләү чарасы ____________________ дип атала.

# 4.3. Лирик жанрлар системасы

БИРЕМ. **Шигырьләрдән алынган өзекләрне укып, аларга туры килгән жанрларны табып әйтегез.**



Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Эзләрем бик иртә салынган.
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Талларыма хәтле сагынган.

«Бу кырлар, бу үзәннәрдә...»,
С. Хәким



Галибанә яктырып,
әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп,
ялкау гына ак ай бата.
Бер-бер артлы юк булып,
күкләрдә йолдызлар сүнә;
Таң җиле куйды исеп,
яфраклар аз-аз селкенә.

«Җәйге таң хатирәсе», Г. Тукай

**ФӘЛСӘФИ ЛИРИКА**

**КҮҢЕЛ ЛИРИКАСЫ**

**ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ**

**ПЕЙЗАЖ ЛИРИКАСЫ**



...Җыя кеше
мал, дан, җыерчыклар, дошман...
Кала барысы:
тирәкләргә сеңеп тавышы кала,
коймаларга сеңеп күләгәсе...

«Җыя кеше...»,
Р. Фәйзуллин



Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

«Җырларым»,
М. Җәлил

**БИРЕМ.** **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән жанрларны атагыз.**

- Ниндидер тарихи вакыйгаларга, җәмгыятьтәге тәртип-мөнәсәбәтләргә, хаксызлыкларга бәйле хис-кичерешләр сурәтләнгән шигырь ________________________________ була.

- Табигатьне сурәтли торган шигырь ____________________ жанрына карый.

- Лирик геройның шәхси тормышы һәм язмышы белән бәйле хис-кичерешләр сурәтләнгән шигырь ________________________ дип атала.

- Тормыш–яшәеш кануннарына мөнәсәбәтле уйланулар, аларны бәяләү үзәккә куелган шигырь ____________________________ була.

# 4.4. Халык авыз иҗаты

БИРЕМ. **Әлеге мисалларга туры килгән жанрларны табып әйтегез.**

«Тургай моңы»






«Кәккүк каян барлыкка килгән»

- **Миф**
- **Әкият**
- **Легенда**
- **Риваять**

«Ак бүре»





«Җил иясе җил чыгара»

**БИРЕМ. Әлеге билгеләмәләргә туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын атагыз.**

- Табигать, тереклек, кешеләр катнашындагы маҗараларны хыял ярдәмендә мавыктыргыч итеп тасвирлый торган жанр ______________________________ була.

- Фантастик образ яки күзаллауга нигезләнгән һәм төрле вакыйга, күренешләрнең сәбәпләрен хыял ярдәмендә аңлата торган жанр – ____________________________________________.

- Тарихи вакыйгаларга, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә халыкның мөнәсәбәтен белдергән әсәр, аңа билгеле бер күләмдә чынбарлыкка якын уйдырмалылык та хас. Бу жанр ______________________________ дип атала.

- Дөньяның килеп чыгышы, кешеләрнең пәйда булуы, Аллаларның, каһарманнарның батырлыгы хакында сөйләнгән яки язылган әсәр ________________________________ дип атала.

# 4.5. Әдәби төрләр

**БИРЕМ.** **Әлеге мисаллар туры килгән әдәби төр атамаларын табып әйтегез.**



«Галиябану»
М. Фәйзи



«Йөзек кашы»
Ф. Хөсни






«Карт имән белән яшь егет»
Ә. Исхак



«Калдыр, аккош, каурыеңны»
И. Юзеев

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән әдәби төрләрне атагыз.**

- Әдәбиятның хис-кичерешләрне белдерүгә, чагылдыруга корылган, аерым осталык һәм махсус чаралар таләп итеппә торган төре ______________________ дип атала.

- Хикәяләү, сюжетлылык, персонажлар системасының хәрәкәт итүе, әйберләр дөньясын детальләрдә сурәтләү кебек үзенчәлекләрне һәм шул ук вакытта хис-кичерешләр тирәнлеген, лирик герой образын яктырткан төрара форма ______________________ дип атала.

- Еш кына кеше, аның язмышы, ул катнашкан, шаһиты булган вакыйгалар хакында детальләп хикәяли, тормышны төрле яклап күрсәтә торган әдәби төр ______________________ дип атала.

- Бердәм хәрәкәт тәшкил иткән вакыйга-күренешләр тормышчан конфликт аша диалог һәм монологларда ачыла торган әдәби төр ______________________ дип атала.

# 4.6. Әкиятләр

**БИРЕМ. Әлеге әкиятләргә туры килгән әкият төрләрен табып әйтегез.**

«Ак бүре»



«Үги кыз»






«Хәйләкәр төлке»



«Шүрәле»



## БИРЕМ. Әлеге билгеләмәләргә туры килгән әкиятләрнең төрләрен атагыз.

- Авторлары билгесез, телдән-телгә күчеп, халык арасында киң таралыш тапкан әкиятләр ______________________ әкиятләре дип атала.
- Авторлары билгеле әкиятләр ______________________ әкиятләр дип йөртелә.
- Сюжет чылбырын хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр тәшкил итә торган, каршылыклар да шулар арасында төгәлләшкән, алар аша кешелеккә тәҗрибә туплау, акыл өйрәтү бурычы куелган, кеше образы беренче планда тормаган әкиятләр ______________________ әкиятләр дип атала.
- Татар халык иҗатында ______________________ әкиятләр күпчелекне тәшкил итә. Аларның күбесенең сюжет чылбыры геройның үсеп буйга җитүе, төрле вакыйгаларга очрап, патша кызын диюдән коткаруы яки патша куйган таләпләрне үтәве, нәтиҗәдә патша кызына өйләнеп, үзенең патша урынында калуы турындагы вакыйгалардан үрелә.
- ______________________ әкиятләре көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән бәйле вакыйгаларны сурәтли, аерым кешеләрнең эчке сыйфатлары хакында сөйли. Бу төрдәге әкиятләр башка төрдәге әкиятләрдән реаль чынбарлыкка бик якын торулары белән аерылып тора.

# 4.7. Җырлар

БИРЕМ. **Җыр исемнәрен укып, аларга туры килгән җыр төрләрен табып әйтегез.**



«Кәрия-Зәкәрия»




«Иске кара урман»

**Тарихи җырлар**

**Йола җырлары**

**Лирик җырлар**

**Уен-бию җырлары**



«Каз канаты»



«Татарстан кызлары»

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән җырларның төрләрен атагыз.**

- Халык авыз иҗатында лирик жанрларның иң киң таралган, сүз-текст белән көйнең үзара үрелүенә нигезләнгән әсәрләр ________________ дип атала.

- Халык, ил тормышындагы зур тарихи вакыйгаларны бәян итүгә корылган һәм аларда катнашучы аерым шәхесләрнең эшчәнлеге, халык бәхете өчен көрәшүчеләр сәнгатьчә сурәтләнә торган җырлар ________________ җырлар дип йөртелә.

- Моңлы итеп, мелизм-бормалар аша ашыкмыйча, тыныч һәм иркен сулыш белән башкарылган җырларны ________________ җырлар дип атыйлар.

- ________________ – татар халкының җыр һәм бию белән аралашкан әйлән-бәйлән уеннарында башкарыла торган җырлар.

- Татар фольклорының Нәүрүз, Нардуган, Сөмбелә, Сабан туе бәйрәмнәрендә әйтелә торган, иген үстерү, яңгыр теләү, шулай ук гаилә-көнкүреш йолаларына бәйле җырлар ________________ дип йөртелә.

# 4.8. Халык авыз иҗатының кече жанрлары

БИРЕМ. **Әлеге мисалларга туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын табып әйтегез.**

«Баскан җиреннән ут чыга»



«Ни чәчсәң – шуны урырсың»



Табышмак

Мәкаль

Әйтем

Мәзәк



Бервакыт Хуҗа Насретдинның күзләре начар күрә башлаган.
– Бөтенләй күрмәскә әйләнсәң, ни хәлләр генә итәрбез? – ди икән хатыны.
– Аптырама, карчык, әлегә түзеп була, сукырайгач, күз күрер тагын, – дигән Хуҗа.



«Акылы юк, җаны бар»

**БИРЕМ. Әлеге билгеләмәләргә туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын атагыз.**

- Халык авыз иҗатының кыскалыкка, юмор-сатирага, көтелмәгәнчә төгәлләнә торган сюжетка корылган иң кечкенә эпик жанрларының берсе ______________________________ дип атала.


- Халык авыз иҗатында афористик жанрларның берсе мәгънәсе ягыннан «сөйләү, әйтеп бирү» дигәнне аңлата. Төгәлләнгән җөмләләрдән тору, образлылык, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп, билгеле бер нәтиҗә чыгару, гыйбрәт, үгет-нәсихәт өчен, дидактик максаттан әйтелү ______________________________ нең төп сыйфатлары булып тора.

- ______________________________ сөйләмне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру вазифасын үти, аерым очракларда модельләштерү функциясе дә күзәтелә. Аларга күчерелмә мәгънәлелек хас, шуннан чыгып аны халык арасында «читләтеп әйтелгән сүз» төшенчәсе белән дә атыйлар.

- ______________________________ – афористик жанрларның берсе. Исеменнән үк аңлашылганча, тыңлаучы алдына асылы читләтеп әйтелгән билгесез әйберне яки күренешне эзләп табу бурычын куя.

# 4.9. Образлар системасы

БИРЕМ. **Әлеге мисалларга туры килгән образ төрләрен табып әйтегез.**



Закир,
«Алмачуар»
Г. Ибраһимов



Староста,
«Алмачуар»
Г. Ибраһимов






Эт эчәгесе,
Канәфер чәчәге,
«Яз әкиятләре»
Г. Рәхим



Ана,
«Матурлык»
Ә. Еники

**БИРЕМ.** **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән образ төрләрен атагыз.**

- Әсәрнең сюжет, вакыйгалар катламын үз тирәсенә җыйган, автор концепциясен тулы һәм төгәл белдерүгә хезмәт итә торган герой ____________________ герой дип атала.

- Хәл-вакыйгаларда катнаша һәм төп геройны ачарга ярдәм итә торган геройны ____________________ герой дип йөртәләр.

- ____________________ геройлар – аерым бер күренеш яки вакыйгаларда гына күренүче персонажлар.

- ____________________ образлар кешегә, тормышка, яшәешкә тирән, гадәттән тыш көчле бәя бирүгә хезмәт итә.

# 4.10. Пафос һәм аның төрләре

БИРЕМ. **Әлеге мисалларга туры килгән пафос төрләрен табып әйтегез.**



«Хәят»
Ф. Әмирхан




«Остазбикә»
Г. Исхакый

«Җомга көн, кич белән»
А. Гыйләҗев



«Вәхшәт»
М. Җәлил








«Матурлык»
Ә. Еники



«Өчәү чыктык ерак юлга»
И. Юзеев

«Җырларым»
М. Җәлил



«Ватаным өчен»
Ф. Кәрим



БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән пафос төрләрен атагыз.**

- Әсәрнең эмоциональ көйләнеше, яңгырашы, аһәңе ____________________ дип атала.
- ____________________________ пафос батырлыкка дан җырлауга, кешенең бөеклеген раслауга йөз тота. Аерым кеше яки кешеләр төркеменең үз идеалларын яклап көрәшү тарихы күрсәтелгән әсәрләрдә кулланыла.
- _____________________________________ пафос – бөеккә, чистага, яктыга омтылудан туган күтәренке рух, ләкин шул омтылышның пассивлыгы китереп чыгарган борчылу, сагыш. Идеалга омтылу, ләкин аның чынбарлык белән туры килмәве яктыртылган әсәрләргә хас.
- ______________________________ пафос – кеше аңында һәм тормышында булган каршылыкларның иң югары ноктага җитүе, үлемгә илтүе.
- _____________________________________ пафос җәлләү, кызгану, аңларга тырышу хисләренең өстенлек алуына нигезләнә.

# 4.11. Тел-сурәтләү чаралары (стилистик фигуралар)

БИРЕМ. **Шигырьләрдән өзекләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне (атамаларны) табып әйтегез.**

Елкы бакты – кол булды,
Өстендә ямар тун булды;
Башы белән баш булды,
Атагы белән дан булды.

«Идегәй» дастаны



Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр...

Ф. Кәрим

**АНАФОРА**
**ЭПИФОРА**
**ГРАДАЦИЯ**
**РИТОРИК ЭНДӘШ**



Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк куралдым.

Һ. Такташ



Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме тал чыбыгы ашадык;
Әкияттәге ике бала кебек,
Күпме «җәфа» чигеп яшәдек.

Һ. Такташ

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне атагыз.**

- Бер үк сүзләрнең, авазларның, сүзтезмәләрнең шигырь юлы башында кабатлануына корылган стилистик фигура ______________________ дип атала.

- Бер үк сүзләрнең, авазларның, сүзтезмәләрнең шигырь юлы ахырында кабатлануына корылган стилистик фигура ______________________ дип атала.

- Мәгънә ягыннан якын сүзләрнең бер-бер артлы тезелеп килүенә нигезләнгән стилистик фигура ______________________ дип атала.

- Шигырь текстында кемгәдер, нәрсәгәдер мөрәҗәгать итеп сөйләү ______________________ дип атала.

# 4.12. Тел-сурәтләү чаралары (троплар)

**БИРЕМ. Шигырьләрдән өзекләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне (атамаларны) табып әйтегез.**



Күңел һәр җирдә гөл эзли,
Тәкъдир һәр җирдә тикән төзли...

Дәрдемәнд



Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомерем өчен сатмадым...

М. Җәлил

**ЧАГЫШТЫРУ**
**ЭПИТЕТ**
**АЛЛЕГОРИЯ**
**СЫНЛАНДЫРУ**



Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел
кыр һәм япан;
Китте инде кап-кара каплап ята
торган чапан.

Г. Тукай



Өс-баш юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.

Ф. Кәрим

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне атагыз.**

- Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтү нигезендә формалашкан тел-сурәтләү чарасы ________________________________ дип атала.

- Күренеш-хәлләрне предмет-сурәтләр белән атауга корылган троп ________________________________________________________ дип атала.

- Әдәби ачыклауга нигезләнгән тел-сурәтләү чарасы ___________________ ________________________________________________________ дип атала.

- Нинди дә булса күренешне аңа охшаш ягы булган икенче күренеш белән чагыштырып сыйфатлау-охшатуга нигезләнгән тел-сурәтләү чарасы ________________________________________________________ дип атала.

# 4.13. Лирик жанрлар системасы

**БИРЕМ. Шигырьләрдән алынган өзекләрне укып, аларга туры килгән жанрларны табып әйтегез.**



Миңа гына шулай тоела микән
Бөтен рәхәтләре соң аның?
Башка берни дә кирәкми,
Үзем тапкан чишмәләрнең
Ятып эчсәм суларын...
«Башка берни дә кирәкми»,
С. Хәким



Сүнеп, вәйран булып мәгъмур
тияклә р,
Җир астында тезелде ку сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комнар...
бетә эз...
Дәригъ, мәхзүн күңел,
без дә бетәбез!
«Без», Дәрдемәнд

**ФӘЛСӘФИ ЛИРИКА**
**КҮҢЕЛ ЛИРИКАСЫ**
**ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ**
**ПЕЙЗАЖ ЛИРИКАСЫ**



Ак чәчәкләр чыңлап тора,
Җырлап тора әйләнәдә.
Ак каеннар сылу-сылу
Яшь кызларга әйләнә дә,
Җыйнаулашып, тезелешеп
Төшеп китә Сөн буена.
Яп-ялангач калып кына
Су керергә төн буена.
«Шундый минем туган ягым»,
Р. Миңнуллин



...Әлифбамны дога итеп
Укыймын күңелемнән.
Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек – бер генә.
«Туган тел», Г. Морат

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән жанрларны атагыз.**

- Ниндидер тарихи вакыйгаларга, җәмгыятьтәге тәртип-мөнәсәбәтләргә, хаксызлыкларга бәйле хис-кичерешләр сурәтләнгән шигырь ______________________________ була.

- Табигать сурәте тудырылган шигырь ______________________ на карый.

- Лирик геройның шәхси тормышы һәм язмышы белән бәйле хис-кичерешләр сурәтләнгән шигырь ______________________ дип атала.

- Тормыш-яшәеш кануннарына мөнәсәбәтле уйланулар, тормыш кануннарын бәяләү үзәккә куелган шигырь ______________________ була.

# 4.14. Тел-сурәтләү чаралары (фоника)

**БИРЕМ.** **Шигырьләрдән өзекләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне (атамаларны) табып әйтегез.**



Каһәрләнгән ике кош шикелле,
Без очабыз таңга кадәрле,
Кычкырабыз:
– Са-а-а-ак!
– Со-о-о-ок!

Зөлфәт



Карасалар карасыннар
Кашларың карасына,
Ят күз укларын үткәрмә
Керфекләр арасына.

Р. Фәйзуллин

**АЛЛИТЕРАЦИЯ**
**АССОНАНС**
**АҺӘҢЛЕЛЕК**
**ОХШАТУ**



Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта –
башкаларны чакырганда
үзе яккан учакка.

Р. Харис



Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез дә кара борынлы,
Зурлар кебек, кулны артка куеп
Йөри идек таптап болынны...

Һ. Такташ

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән теоретик төшенчәләрне атагыз.**

- Шигырьдәге матур, гармонияле яңгыраш ______________________ дип атала.

- Тартык аваз хәрефләре кабатлануга корылган фонетик чара ______________________ дип атала.

- Сузык аваз хәрефләре кабатлануга корылган фонетик чара ______________________ дип атала.

- Текстта ниндидер күренешләрне авазлар ярдәмендә күз алдына бастыру ______________________ дип атала.

# 4.15. Лиро-эпик жанрлар

БИРЕМ. **Әсәрләргә туры килгән лиро-эпик жанрларны табып әйтегез.**



«Карт имән белән яшь егет», Ә. Исхак



«Сандугач һәм чишмә», М. Җәлил



«Сагыну», Г. Кутуй



«Сәйдәш», Р. Фәйзуллин

**Поэма**

**Мәсәл**

**Баллада**

**Нәсер**

**БИРЕМ. Әлеге билгеләмәләргә туры килгән лиро-эпик жанрларны атагыз.**


- Эмоциональлеге, ритмик төзелеше ягыннан шигъри сөйләмгә якын, хис-кичереш эволюциясен күрсәтә торган чәчмә әсәр _________________________ дип йөртелә.
- Геройларны уңайга һәм тискәрегә бүлеп, кискен каршылыкта сурәтли торган романтик, символик-аллегорик характердагы сюжетка корылган әсәр – _________________________.
- Тормыштагы гыйбрәтле яки кимчелекле күренешләрне, капма-каршы холык сыйфатларын аллегорик образлар бәрелешендә күрсәтә, әхлакый гомумиләштерү белән тәмамлана торган лиро-эпик әсәр _________________________ дип атала.
- Сюжеты лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп барган, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелгән лиро-эпик әсәр _________________________ дип атала.

# 4.16. Халык авыз иҗаты

**БИРЕМ. Әсәрләргә туры килгән жанрларны табып әйтегез.**



«Гөлҗамал»



«Сак-Сок»



«Өч кыз»



«Шәһәр нигә Казан дип аталган»

**Риваять**

**Әкият**

**Бәет**

**Җыр**

**БИРЕМ.** **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын атагыз.**

- Зур күләмле, гади яисә катлаулы, мавыктыргыч, маҗаралы, ярымфантастик эпик әсәр. Атамасы гарәп теленнән тәрҗемәдә «сөйләп бирү» мәгънәсен аңлата. Мондый жанр ______________________ була.

- Халык авыз иҗатында лирик жанрларның иң киң таралганы, сүз-текст белән көйнең үзара үрелүенә нигезләнгән әсәрләр –________________ .

- Күп очракта тарих түгел, бәлки тарихи вакыйгаларга, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә халыкның мөнәсәбәте буларак формалаша. Уйдырмалылык билгеле бер урын ала, ләкин, әкият, легенда, мифологик хикәятләрдән аермалы буларак, уйдырма нигездә, реальлеккә якын тора. Бу жанр ______________________________________________ дип атала.

- Татар халык иҗатының нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган лиро-эпик жанры. Әсәр шул вакыйга тәэсирендә герой күңелендә туган хис-кичерешләрне бәян итә. Бу жанр ____________________ дип атала.

# 4.17. Әкиятләр

**БИРЕМ.** **Әкиятләргә туры килгән әкият төрләрен табып әйтегез.**

«Таңбатыр»



«Өч кыз»



Хайваннар турындагы әкиятләр

Тылсымлы әкиятләр

Әдәби әкиятләр

Тормыш-көнкүреш әкиятләре



«Батыр әтәч»



«Зәңгәр күлдә ай коена»

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән әкиятләрнең төрләрен атагыз.**

- Авторлары билгесез, телдән-телгә күчеп, халык арасында киң таралыш тапкан әкиятләр ________________________________ әкиятләре дип атала.
- Авторлары билгеле әкиятләр ________________________________ әкиятләр дип йөртелә.
- Сюжет чылбырын хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр тәшкил итә торган, каршылыклар да шулар арасында төгәлләшкән, алар аша кешелеккә тәҗрибә туплау, акыл өйрәтү бурычы куелган, кеше образы беренче планда тормаган әкиятләр ________________________________ әкиятләр дип атала.
- Татар халык иҗатында ____________________ әкиятләр күпчелекне тәшкил итә. Аларның күбесенең сюжет чылбыры геройның үсеп буйга җитүе, төрле вакыйгаларга очрап, патша кызын диюдән коткаруы яки патша куйган таләпләрне үтәве, нәтиҗәдә патша кызына өйләнеп, үзенең патша урынында калуы турындагы вакыйгалардан үрелә.
- ________________________________ әкиятләре көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән бәйле вакыйгаларны сурәтли, аерым кешеләрнең эчке сыйфатлары хакында сөйли. Бу төрдәге әкиятләр башка төрдәге әкиятләрдән реаль чынбарлыкка якынлыгы белән аерылып тора.

# 4.18. Халык авыз иҗатының кече жанрлары


**БИРЕМ.** **Әлеге мисалларга туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын табып әйтегез.**



– Фәрди, нишләп сездә арпа үсми?
– Чәчмәгәч!..
– Ә нишләп чәчмисез?
– Үсмәгәч!..

«Үзе яңа – үзе тишек»








«Туган илең – туган анаң, чит ил – үги анаң»

«Акылың алтын икән»



БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән халык авыз иҗаты жанрларын билгеләгез.**

- Халык авыз иҗатының кыскалыкка, юмор-сатирага, көтелмәгәнчә тәгәлләнә торган сюжетка корылган иң кечкенә эпик жанрларының берсе ________________________________ дип атала.
- Халык авыз иҗатында афористик жанрларның берсе мәгънәсе ягыннан «сөйләү, әйтеп бирү» дигәнне аңлата. Тәгәлләнгән җөмләләрдән тору, образлылык, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп, билгеле бер нәтиҗә чыгару, гыйбрәт, үгет-нәсихәт өчен, дидактик максаттан әйтелү һ. б. ________________________ нең төп сыйфатлары булып тора.
- ____________________ сөйләмне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру вазифасын үти, аерым очракларда модельләштерү функциясе дә күзәтелә. Аларга күчерелмә мәгънәлелек хас, шуннан чыгып аны халык арасында «читләтеп әйтелгән сүз» төшенчәсе белән дә атыйлар.
- ____________________________ – афористик жанрларның берсе. Исеменнән үк аңлашылганча, тыңлаучы алдына асылы читләтеп әйтелгән билгесез әйберне яки күренешне эзләп табу бурычын куя.

# 4.19. Әдәби төрләр

**БИРЕМ.** **Әсәрләргә туры килгән әдәби төрләрне табып әйтегез.**



«Сандугач һәм чишмә»
М. Җәлил



«Сәйдәш»
Р. Фәйзуллин



«Сез иң гүзәл кеше икәнсез»
Ф. Яруллин



«Туган авыл»
Г. Тукай

Эпик төр

Лирик төр

Драма төре

Лиро-эпик төрара форма



«Яз әкиятләре»
Г. Рәхим



«Кояш артыннан киткән тургай»
И. Гази



«Әлдермештән Әлмәндәр»
Т. Миңнуллин



«Беренче театр»
Г. Камал

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән әдәби төрләрне атагыз.**

- Әдәбиятның хис-кичерешләрне белдерүгә, чагылдыруга корылган, аерым осталык һәм махсус чаралар таләп ителәә торган төре ______________________________ дип атала.

- Хикәяләү, сюжетлылык, персонажлар системасы хәрәкәт итү, әйберләр дөньясын детальләрдә сурәтләү кебек үзенчәлекләрне һәм шул ук вакытта хис-кичерешләр тирәнлеген, лирик герой образын яктырткан төрара форма ______________________________ дип атала.

- Еш кына кеше, аның язмышы, ул катнашкан, шаһиты булган вакыйгалар хакында детальләп хикәяли, тормышны төрле яклап күрсәтә торган әдәби төр ______________________________ дип атала.

- Бердәм хәрәкәт тәшкил иткән вакыйга-күренешләр тормышчан конфликт аша диалог һәм монологларда ачыла торган әдәби төр ______________________________ дип атала.

# 4.20. Эпик жанрлар

**БИРЕМ.** **Әсәрләргә туры килгән жанр атамаларын табып әйтегез.**



«Урман кызы Таңсылу»
Г. Сабитов



«Матурлык»
Ә. Еники

**Хикәя**

**Повесть**

**Роман**

**Әдәби әкият**



«Беренче умырзая»
Р. Мөхәммәдиев



«Тукай»
Ә. Фәйзи

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән жанрларны атагыз.**

- Бер яки берничә вакыйганы үз эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, ягы, аның үсү-үзгәрүе хакында сөйли торган эпик жанр ____________________________________________ дип атала.
- Язма әдәбиятка фольклордан күчеп, әхлакый типиклаштыру сыйфаты калку күренеп торган әсәр ________________________________ дип атала.
- Төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар тезмәсе сурәтләнгән, берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшкән әсәр__________________________ дип атала.
- Аерым кешеләрнең шәхси теләк-омтылышлары, язмышы һәм тирәлек белән бәрелеше сурәтләнгән, шулар аша кеше һәм җәмгыятькә бәя бирелә, холык-фигыль ачыла торган зур күләмле эпик жанр ___________________ дип атала.

# 4.21. Эпик жанрлар


БИРЕМ. **Әсәрләргә туры килгән жанр атамаларын табып әйтегез.**



«Ак сирень»
И. Гази



«Онытылмас еллар»
И. Гази



«Без – кырык беренче ел балалары»
М. Мәһдиев



«Буранда»
Ш. Камал

**Новелла**

**Повесть**

**Роман**

**Хикәя**

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән жанрларны атагыз.**

- Аерым кешеләрнең шәхси теләк-омтылышлары, язмышы һәм тирәлек белән бәрелеше сурәтләнгән, шулар аша кеше һәм җәмгыятькә бәя бирелә, холык-фигыль ачыла торган зур күләмле эпик жанр ______________________________ дип атала.
- Бер яки берничә вакыйганы үз эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, ягы, аның үсү-үзгәрүе хакында сөйли торган эпик жанр ______________________________ дип атала.
- Төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар тезмәсе сурәтләнгән, берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшкән әсәр ______________________________ дип атала.
- Гадәти булмаган вазгыятькә корылган, көтелмәгәнчә тәмамлана, чишелеш вакытында геройның яңа якларын ачып тетрәнергә мәҗбүр итә торган эпик жанр ______________________________ дип атала.

# 4.22. Әдәби алымнар

БИРЕМ. **Әсәрләрдәге төп сурәт тудыру алымына туры килгән төшенчәләрне атагыз. Әсәрләрдән шушы төшенчәләргә туры килгән урыннарны табып укыгыз.**



Акъәби сурәте,
«Әйтелмәгән васыять»
Ә. Еники



Егет образы,
«Кем җырлады?»
Ә. Еники

**Пейзаж**

**Портрет**

**Әдәби деталь**

**Психо-логизм**



Яз сурәте,
«Яз»
Н. Арсланов



Тарак образы,
«Яшь ана»
Н. Думави

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән әдәби төрләрне атагыз.**

- Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау ____________ дип атала.
- Әсәрдә җанлы һәм җансыз табигатьне (тышкы дөньядагы ачык пространствоны) сурәтләү ____________ дип йөртелә.
- Кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә торган алымнар берлеге; язучының кеше күңеленә үтеп керү, аның халәт-кичерешен сурәтләү осталыгы ____________ дип атала.
- Әдәби әсәр тудыруда катнаша торган әйбер, предмет, сызык, төс, хәрәкәт, күренеш ____________ дип йөртелә.

# 4.23. Әдәби алымнар

БИРЕМ. **Әсәрләрдәге төп сурәт тудыру алымына туры килгән төшенчәләрне атагыз. Әсәрләрдән шушы төшенчәләргә туры килгән урыннарны табып укыгыз.**



«Яшьлегемне эзлим», табигать сурәте

Ә. Баян



«Татар кызына», татар кызы образы

Ш. Җиһангирова






«Йөзек кашы», йөзек образы

Ф. Хөсни



«Көз»

Г. Исхакый

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән төшенчәләрне атагыз.**

- Күпсанлы ассоциатив сыйфатларны берләштерә, күпмәгънәле, гомуми, туры мәгънәсеннән тыш, аңа бәйле булмаган күчерелмә мәгънәләрне аңлата, ләкин шуның янәшәсендә башка мәгънәләр дә сиземләнә торган образ ______________________________ дип атала. Аның аллегориядән аермасы – мәгънәләрнең берничә булуында.

- Әдәбиятта чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт берлеге ______________________________ дип атала.

- Әсәрдә җанлы һәм җансыз табигатьне (тышкы дөньядагы ачык пространствоны) сурәтләү______________________ дип йөртелә.

- Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау ______________ дип атала.

# 4.24. Тема төрләре

БИРЕМ. **Әлеге мисалларда чагылган төп теманың төрен табып әйтегез.**



«Туган ягым – яшел бишек»
Г. Бәширов



«Идегәй» дастаны






«Исемдә калганнар»
Г. Тукай

«Әлдермештән Әлмәндәр»
Т. Миңнуллин



И туган тел, и матур тел...

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән тема төрләрен билгеләгез.**

- Төрле заман һәм халыклар өчен уртак, кызыклы, әһәмиятле тема ________________________________ тема дип атала.
- Аерым бер этник төркемгә, халыкка гына хас, башкалар өчен закончалыклы булмаган тема ________________________ тема дип атала.
- Билгеле бер вакыт яисә чордагы әһәмиятле тарихи вакыйгалар йогынтысында туган тема _________________________тема дип йөртелә.
- Биографик һәм автобиографик әсәрләрдә үз-үзеңне танып белүгә мөнәсәбәтле тема ________________________________тема дип атала.

ӘДӘБИ НУРЛАР

# 4.25. Проблема төрләре

БИРЕМ. **Әлеге мисалларда чагылган төп проблеманың төрен табып әйтегез.**



«Әлдермештән Әлмәндәр»
Т. Миңнуллин



«Йөзек кашы»
Ф. Хөсни



«Җидегән чишмә»
Г. Бәширов



«Әйтелмәгән васыять»
Ә. Еники

**Иҗтимагый проблема**

**Милли проблема**

**Фәлсәфи проблема**

**Кеше проблемасы**

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән тема төрләрен билгеләгез.**

- Җәмгыять тормышындагы аерым яклар белән бәйле мәсьәләләр ______________________ проблема дип йөртелә.
- Милли сыйфатлар, яшәү рәвеше, характер үзенчәлекләре белән бәйле мәсьәләләр ______________________ проблема дип атала.
- Кешелек, яшәү мәгънәсе, яшәеш кануннарына бәйле сораулар ______________________ проблема дип йөртелә.
- Шәхескә, аңардагы үзгәрешләргә, шәхси сыйфатларына бәйле мәсьәләләр ______________________ проблемасы дип атала.

# 4.26. Пафос һәм аның төрләре

БИРЕМ. **Әсәрләргә туры килгән пафос төрләрен табып әйтегез.**



«Беренче театр»
Г. Камал



«Ватаным өчен»
Ф. Кәрим

**Драматик пафос**

**Сатирик пафос**

**Комик пафос**

**Героик пафос**



«Җан Баевич»
Г. Исхакый



«Буранда»
Ш. Камал

## БИРЕМ. **Әлеге билгеләмәләргә туры килгән пафос төрләрен билгеләгез.**

- Әсәрнең эмоциональ көйләнеше, яңгырашы, аһәңе ____________________ дип атала.

- ______________________________ пафос батырлыкка дан җырлауга, кешенең бөеклеген раслауга йөз тота. Аерым кеше яки кешеләр төркеменең үз идеалларын яклап көрәшү тарихы күрсәтелгән әсәрләрдә актив кулланыла.

- ______________________________ пафос – кешенең иҗтимагый һәм шәхси тормышындагы каршылыкларын аңлаудан туган курку, борчылу, сызлану.

- ______________________________ пафос – тормышның (шәхси, иҗтимагый) аерым бер якларын тәнкыйтьләп көлү, кире кагу, мыскыл итү.

- ______________________________ пафос зур булмаган кимчелекләрдән яратып, асылда җылы көлүгә нигезләнә.

Белем бирү системасындагы үзгәрешләр, яңарыш, әдәбият укытуда үзгә педагогик технологияләр системасы барлыкка килү яңа төр кулланмалар төзү, татар әдәбиятын өйрәнүнең кызыклы юлларын, яңа мөмкинлекләрен эзләү ихтыяҗын көн тәртибенә куйды. Шушы юлда татар әдәбиятыннан бер тәҗрибә буларак тәкъдим ителә торган әлеге проект гомуми урта һәм төп белем бирү мәктәпләре укучыларына, укытучыларга йөз тотып эшләнде. Гамәли юнәлешле әлеге кулланманың төп максаты – укучыларның әдәби белемнәрен системага салырга ярдәм итү, теге яки бу әдипнең тормыш һәм иҗат биографиясе хакындагы мәгълүматларны тулыландыру, теоретик белемнәрне гамәлдә кулланырга булышу.

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО